МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.04.2016 № 152-пр

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмаларыннан, сәяси партияләрдән, башка иҗтимагый берләшмәләрдән һәм дини берләшмәләрдән мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул итеп алу тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затларның чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка төрле аерымлылык билгеләрен кабул итеп алуы тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 10 октябрендәге 506 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты билгеләп куя һәм азат итә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм башка төрле аерымлылык билгеләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2016 елның 12 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмаларыннан, сәяси партияләрдән, башка иҗтимагый берләшмәләрдән һәм дини берләшмәләрдән мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул итеп алу тәртибен расларга.

2. Кадрлар бүлеге мөдиренә (Газизов Р.М.) әлеге Боерык белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм хезмәт контракты төзелгән

гражданнарның танышуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
1 апрель 2016 ел N 152-пр
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмаларыннан, сәяси партияләрдән, башка иҗтимагый берләшмәләрдән һәм дини берләшмәләрдән мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул итеп алу тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – граждан хезмәткәре, Министрлык) чит ил дәүләтләреннән, халыкара оешмаларыннан, сәяси партияләрдән, башка иҗтимагый берләшмәләрдән һәм дини берләшмәләрдән мактаулы һәм махсус исемнәр (фәннидән тыш), бүләкләр кабул итеп алу процедурасын билгели, әгәр күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек итү граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына керсә (алга таба – исемнәр, бүләкләр).

2. Граждан хезмәткәре исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы Бир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрыннан (алга таба – Министр) рөхсәт алырга тиеш

3. Исем, бүләк алган яки чит ил дәүләтеннән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән, дини берләшмәдән исем яки бүләк бирелүе турында хәбәр алган граждан хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар бүлегенә Министр исеменә чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алуга рөхсәт бирү турында бу Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә төзелгән үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) тапшыра.

Үтенечнамәне карау вакыты үтенечнамәне әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә кадрлар бүлегендә теркәгән көннән башлап ун эш көне тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләктән баш тарткан граждан хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар бүлегенә чит ил дәүләтенең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы һәм махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән формада тутырылган хәбәрләмә (алга таба – хәбәрләмә) тапшыра..

5. Исем, бүләк алган граждан хезмәткәре, үтенечнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан карар кабул ителгәнче, исемгә документларның төп нөсхәләрен һәм бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен, аларны алганнан соң өч эш көне эчендә, Министрлыкның эшләр белән идарә итүчесенә җаваплы саклауга тапшыра. Шул ук вакытта бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

6. Граждан хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләк алганда

яки алардан баш тарткан очракта, үтенечнамә яки хәбәрләмә тапшыру вакыты граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән башлап исәпләнелә.

7. Граждан хезмәткәре, үзенә бәйсез сәбәп аркасында, үтенечнамәне яки хәбәрләмәне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен бу Тәртипнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаган очракта, үтенечнамәне яки хәбәрләмәне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәп юкка чыгарылганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне (хәбәрләмәне) теркәү кадрлар бүлеге тарафыннан аны кабул итеп алган көнне бу Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә төзелгән теркәү журналында башкарыла. Ике эш көне эчендә теркәлгән үтенечнамә (хәбәрләмә) Министрга карап тикшерүгә җибәрелә.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә үтенечнамәне (хәбәрләмәне) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм аңа, Министр резолюциясе белән, үтенечнамәнең (хәбәрләмәнең) билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Үтенечнамәнең (хәбәрләмәнең) министр резолюциясе куелган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

10. Граждан хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсе Министр тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта, Министрлыкның эшләр белән идарә итүчесе 10 эш көне эчендә граждан хезмәткәренә исемгә документларны төп нөсхәләрен, бүләк һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Шул ук вакытта бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

11. Граждан хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен министр канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, кадрлар бүлеге 10 эш көне эчендә исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең тиешле органына җибәрә.

мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләре тарафыннан чит ил
дәүләтләреннән, халыкара
оешмаларыннан, сәяси партияләрдән,
башка иҗтимагый берләшмәләрдән
һәм дини берләшмәләрдән мактаулы
һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул
итеп алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры
А.К.Хамаевка

________________________
(вазифа атамасы)

__________________________

__________________________
(Ф.И.О., адрес, телефон номеры)

Чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алырга рөхсәт бирү турында
үтенечнамә

Миңа кабул итеп алырга рөхсәт бирүне сорыйм
______________________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең исеме)

______________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

______________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

______________________________________________________________________________

Мактаулы яки махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар (кирәклесенең астына сызарга)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең исеме)

______________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар атамасы)

«____»________ 20___ел №___ кабул итеп алу-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгының эшләр белән идарә итүчесенә тапшырылды.

«__»___________20 ел __________________ _______________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләре тарафыннан чит ил
дәүләтләреннән, халыкара
оешмаларыннан, сәяси партияләрдән,
башка иҗтимагый берләшмәләрдән
һәм дини берләшмәләрдән мактаулы
һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул
итеп алу тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры
А.К.Хамаевка

________________________
(вазифа атамасы)

__________________________

__________________________
(Ф.И.О., адрес, телефон номеры)

Чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алудан баш тарту турында
хәбәрләмә

Түбәндәгене алудан баш тарту турында карар кабул итүемне җиткерәм
________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең исеме)

______________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

____________________ 20 ел __________ __________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм

мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләре тарафыннан чит ил
дәүләтләреннән, халыкара
оешмаларыннан, сәяси партияләрдән,
башка иҗтимагый берләшмәләрдән
һәм дини берләшмәләрдән мактаулы
һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул
итеп алу тәртибенә 3 нче кушымта

Кабул итеп алу-тапшыру
акты

__________________20___ел. №________________

Без,түбәндә имза куючылар акт төзедек, түбәндәге хакында:

(ФИӘИ, вазыйфасы) тапшырды/кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга), ә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының эшләр белән идарә итүчесе _________________________кабул итте/тапшырды (кирәклесе астына сызарга), түбәндәгеләрне:
(ФИӘИ)

| N п/п | Атама | Саны (данә) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды Кабул итеп алды

__________________________________ ___________________________________
(имза, тулы имза) (имза, тулы имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләре тарафыннан чит ил
дәүләтләреннән, халыкара
оешмаларыннан, сәяси партияләрдән,
башка иҗтимагый берләшмәләрдән
һәм дини берләшмәләрдән мактаулы
һәм махсус исемнәр, бүләкләр кабул
итеп алу тәртибенә 4 нче кушымта

Үтенечнамәләрне (хәбәрләмәләрне) исәпкә алу
журналы

| N | Үтенечнамә (хәбәрләмә) тапшырган граждан хезмәткәренең ФИӘИ | Үтенечнамә (хәбәрләмә) тапшырган граждан хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенечнамә (хәбәрләмә) килгән дата | Бүләкнең, исемнең аталышы | Кабул итеп алу-тапшыру актының реквизитлары (булган очракта) | Үтенечнамә (хәбәрләмә) кабул иткән затның ФИӘИ, имзасы | Үтенечнамә (хәбәрләмә) тапшырган затның ФИӘИ, имзасы | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |